ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 231-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы <u>КАРАР БИРӘ:</u>

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 231-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2021 елның 5 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2021 елның 1 декабренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 25 октябре
№ 1164-VI ДС